Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең
Дербедень авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

3 август 2026 ел №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2026 елның 03 августында 17 сәгать 00 минутта узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге бюджетына 2026 елда кергән 335 000 сум 00 тиенлек гражданнарның үзара салым акчаларын «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 28 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2 номерлы гражданнар җыенында кабул ителгән карарларга нигезләнеп, «торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга (Совет урамында дренаж торбасын төзекләндерүгә), Дербедень авылындагы вак таш юллардагы чокырларны ремонтлауга» дип билгеләнгән, җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишәргә «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны проектлауга, төзүгә һәм ремонтлауга һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (сууткәргечне алыштыруны) тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын» юнәлдерү белән килешәсезме? соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 73 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 46 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 46 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге бюджетына 2026 елда кергән 335 000 сум 00 тиенлек гражданнарның үзара салым акчаларын «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 28 октябрендәге 1 номерлы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2 номерлы гражданнар җыенында кабул ителгән карарларга нигезләнеп, «торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга (Совет урамында дренаж торбасын төзекләндерүгә), Дербедень авылындагы вак таш юллардагы чокырларны ремонтлауга» дип билгеләнгән, җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишәргә «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны проектлауга, төзүгә һәм ремонтлауга һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (сууткәргечне

алыштыруны) тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын» юнәлдерү белән килешәсезме? соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Дербедень авылы, Совет урамы, 32а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Э.Р. Морозова